КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 7 сентябрь г.Казань № 799

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашкан инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1323 нче карары белән расланган Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашкан инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашкан инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1323 нче карары белән расланган Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашкан инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидия бирү турында шартнамә төзү хокукына субсидия бирү турында шартнамә төзү өчен гариза бирергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган оешмалар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (туплау) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (туплау) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш), индивидуаль эшмәкәрләр, крестьян (фермер) хуҗалыклары (алга таба – эш бирүчеләр) ия:

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында башка үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмау;

«бетерү, үзгәртеп оештыру процессында булмау, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмау (юридик затлар өчен), индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмау (индивидуаль эшмәкәрләр өчен);

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 процenttан артып киткән Россия юридик затлары булмау;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар булмау;

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып бара.»;

4 нче пунктта:

беренче абзацта «Субсидия күләме» сүзләреннән соң «(S, сум)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

6 нчы пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шартнамәдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидияне күчерү тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең өстәмә хисаплылык вакытларын һәм формасын билгеләргә хокукы, эш бирүче тарафыннан субсидияне кире кайтару очраклары, тәртибе, вакытлары, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан эш бирүченең субсидия

биру шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыру, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан эш бирүченең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы, эш бирүченең бу Тәртип һәм төзелә торган шартнамә шартларын үтәве турында нигезләмәләр, шартнамәнең шартларын бозган өчен җаваплылык, эш бирүченең һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең бу Тәртиптә каралган башка шартлары һәм бурычлары карала.

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кирәк булганда, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм эш бирүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча шартнамәгә өстәмә килешү, шул исәптән шартнамәне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Шартнамә төзү өчен эш бирүче, агымдагы елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашкан инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында шартнамә төзүгә гариза (алга таба – гариза) бирә. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

бу Тәртипнең 4 нче пункты нигезендә башкарылган субсидия күләменең исәп-хисабы;

шартнамә төзү өчен гариза бирергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче көненә эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасы куелган, эш бирүченең мөһере (мөһере булганда) белән расланган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау турында белешмә кәгазе;

шартнамә төзү өчен гариза бирергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче көненә эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасы куелган эш бирүченең бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

шартнамә төзү өчен гариза бирергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче көненә эш бирүченең җитәкчесе (индивидуаль эшмәкәр) имзасы куелган һәм мөһер (мөһере булганда) белән расланган эш бирүченең үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын (юридик затлар), индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмавын раслый торган белешмә кәгазе.

Эш бирүче үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен, йә физик затны индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык

күчермәсен, йә Юридик затларның (индивидуаль эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестры язмасы бите күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә заявка белән мөрәҗәгать иткәнгә кадәр өч айдан да иртәрәк булмаган вакыт эчендә бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә) күчермәсен;

салым органының шартнамә төзүгә гариза бирергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче көненә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау турында белешмә кәгазе.

Эш бирүче тарафыннан бу пунктның җиденче – унынчы абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

14 нчы пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүче тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 11 нче пунктында каралган таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);»;

17 нче пунктта «нәтиҗәлелек күрсәткече» сүзләрен «нәтиҗәсе» сүзенә алыштырырга, «эш бирүченең субсидия бирү турында килешү төзү турындагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

18 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисапны эш бирүче ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10ысыннан да соңга калмыйча, бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшыра.»;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, эш бирүчегә субсидия бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан  башкарылган чыгымнар турында һәм эш бирүче тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында Министрлыкка хисап тапшыра.»;

21 нче пунктта:

беренче абзацта «субсидияләр алучылар» сүзләрен «эш бирүчеләр» сүзләренә алыштырырга;

икенче абзацта «субсидия алучылар» сүзләрен «эш бирүчеләр» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия суммасыннан 1 процент күләмендә – шартнамәдә каралган субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешмәгән өчен.»;

23 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан эш бирүчеләргә субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы эш бирүчеләр тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.»;

кушымтаның башисемендә «кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алыштырырга;

2 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашкан инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 7 сентябрь, 799 нчы боерыгы редакциясендә)

Форма

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

| Нәтиҗәнең исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Күрсәткеч-нең план буенча мәгънәсен үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | исеме | коды | | | | |
| Эш бирүченең шартнамә төзү турындагы гариза-сында күрсәтелгән инвалидларның фаразлана торган санының эшкә ка-бул ителгән инва-лидлар санына туры килүе яисә артып китүе | кеше | 792 | | | | |

____________________ ________________________________________
(җитәкченең вазыйфасы) (җитәкченең имзасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)

М.У.[1]

Баш бухгалтер ____________ _______________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

20__ ел, «___» ___________

[1] Мөһер булганда.